РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4079

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү һәм капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 3 июнендәге 1961 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

БАШКАРАМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү һәм капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 3 июнендәге 1961 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 бүлегендә:

- 2.5.2 пунктының 2.4.1.1 пунктын, 6, 7 пунктчаларын төшереп калдырырга;

- 2.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча өстәргә:

«4) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм функцияләре булган дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдаланып»;

карарның 3 бүлегендә:

- 3.5.3 пунктта «комитет рәисе» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары (ышанычнамә буенча вәкил)» сүзләренә алмаштырырга»;

заказ № 1-851

- карарга 6 нчы кушымтаны төшереп калдырырга;
- карарга кушымтаны (белешмә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү һәм капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү турында хәбәр итү юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен тикшереп торучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты

| Ф.И.О. | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Сәлимгәрәев Илсур Илдус улы | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары | 39-01-30 | Almat@tatar.ru |

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы

| Ф.И.О. | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Кузьмина Татьяна Николаевна | Комитет рәисе вазыйфаларын башкаручы | 43-86-88 | pzio@mail.ru |
| Украинская Юлия Илгиз кызы | Шәһәр төзелеше эшчәнлеге һәм төзелеш комитеты рәисе урынбасары | 32-00-12 | uag_6@mail.ru |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Г.М. Хәбутдинова